Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№6 (99)
6 март 2014 ел

# Студентларга яз «килде»!



Фотода: студентлар фестивальгә әзерлек барышында. Влад Михневский фотосы.

Яз житкәч, кеше яңа сулыш белән яши башлый. Кәефләр шәп, хәтта түбәдән тамган тамчылар да сөенә кебек, кояш та бөтен җылылыгын биреп балкый. Бик тиздән язның беренче бәйрәме – гүзәл затларыбызны зурлау көне дә килеп житә. Ә УНИКС концертлар залы сәхнәсе язның беренче көннәреннән үк җылылыкка, илһамга чумган иҗади, яңа идеяле студентлар белән бизәлде. 5 март көнне «Студент язы – 2014» фестивале марафонын Философия факультеты һәм Идарә һәм территориаль үсеш институты башлап җибәрде. Язның беренче аеның һәр көнендә диярлек уку йортыбыз студентларының дөртле чыгышларын күзәтә алачаксыз.



*Илшат Гафуров,*
*КФУ ректоры*

*Хөрмәтле хатын-кызлар!*

**Сезне Халыкара хатын-кызлар көне – 8 март бәйрәме белән тәбрик итәм!**



Бу көнне без гүзәллегегезгә, акылыгызга, тормышның көндәлек һәм иҗтимагый проблемаларын җиңел хәл итүегезгә тагын да күбрәк сокланабыз. Сезнең игътибарыгыз һәм кайгыртучан булуыгыз ир-атларны илһамландыра, аларны яхшырак һәм көчлерәк итә. Сез – шатлыклы вакытларда безне канатландыручы, авыр чакларда терәк булучылар! Сезнең кайгыртуыгыз аркасында җан җылысы һәм мәхәббәт, ана бөеклеге һәм туган йортның ямьлелеге кебек кыйммәтләр мәңгеләштерелә.

Бүгенге язгы һәм матур бәйрәмдә иң авыр мәсьәләләрне дә хәл итә алырдай замана хатын-кызының эшлекле сыйфатлары һәм традицион гаилә кыйммәтләре бергә килеп тоташа. Бүгенге көндә асыл затларыбызның һөнәри һәм иҗади үсеше өчен барлык кирәкле шартлар да булдырылган. Шуңа күрә хатын-кызлар төрле өлкәләрдә: мәгариф яисә фән, икътисад яки сәясәт, иҗат яисә спортмы – зур уңышка ирешәләр. Безнең коллектив хатын-кызларына университетның зур темплар белән үсешенә керткән бәяләп бетергесез хезмәтләре өчен чиксез рәхмәт әйтәсем килә. Сез – безнең кадерле хәзинәбез һәм горурлыгыбыз!

Алдагы һәр көнегез бәхет, шатлык һәм күңелле мизгелләрдән торсын. Ныклы сәламәтлек, иминлек, һәр эшегездә уңышлар телим!

## Вакыйгалар эзеннән

Шушы көннәрдә Казан педагогия көллиятенең актлар залында 1944 елда барган сугыш вакыйгаларына, Ленинградны фашистлар чолганышыннан азат итүгә 70 ел, Әфганстаннан совет гаскәрләрен чыгаруга 25 ел тулуга багышланган **ФӘННИ-ПРАКТИК КОНФЕРЕНЦИЯ БУЛДЫ**. Аның эшендә сугыш һәм тыл ветераннары, КФУ галимнәре, көллият укытучылары, студентлар, Татарстанның Әлки, Кукмара, Чистай, Бөгелмә, Саба районнарыннан килгән укытучылар, укучылар катнашты.

• • • •

**28 ФЕВРАЛЬ** көнне Казан университетында «Bridging Languages and Cultures» **I РЕСПУБЛИКА ЛИНГВИСТИК ФОРУМЫНЫҢ ТАНТАНАЛЫ АЧЫЛЫШЫ БУЛДЫ**. Аны уку йортыбызның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты оештырган. Бирегә, белем эстәү өчен, республикабызның 29 районыннан 47 мәктәп, гимназия һәм лицейларыннан 300дән артык укучы җыелган иде.

• • • •

**4 МАРТ** көнне А.М.Бутлеров ис. Химия институтында Tor Vergata (Рим, Италия) профессоры **ДЖУЗЕППЕ ПАЛЛЕСКИНЫҢ** «Электрохимик биосенсорлар: теориядән алып практикага кадәр» дип исемләнгән **ЛЕКЦИЯСЕ БУЛДЫ**. Чыгышын башлап җибәргәнче, кунак Рим буенча визуаль экскурсия үткәрде, үзенең университеты турында беркадәр мәгълүмат бирде. Аннан соң Казан университеты тыңлаучылары өчен лекциясен тәкъдим итте.

• • • •

Франциядә үткән Salon de l'Etudiant халыкара күргәзмәсендә катнашканы өчен, **КФУ РФНЕҢ МӘГАРИФ һӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ ДИПЛОМЫ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘНДЕ**. Әлеге белем бирү технологияләре һәм хезмәтләре күргәзмәсе Париж шәһәрендә февраль башында булган иде. Анда Казан университеты «Россия университетлары. Мәгариф, фән һәм инновацияләр» РФнең Мәгариф һәм фән министрлыгының комплекслы экспозициясендә Россиянең башка 12 югары уку йорты белән беррәттән тәкъдир ителде.

**Ахыры 2нче биттә.**

• Гүзәл затлар

# «Яратуның артыгы булмый, ратканнан кеше бозылмый...»

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Университетта уку – кеше тормышының алтын чоры икән ул. Моны мин әле күптән түгел, бишенче курс азагында гына аңлый башладым. Күпме яңа таныш-белеш, биш ел уку дәверендә якын дусларга әверелгән төркемдәшләр, безне укыту-тәрбияләүгә зур көч куйган мөгаллимнәребез... Һәр студентның аеруча да яраткан, хөрмәт иткән, сокланган укытучылары була торгандыр. Филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты доценты, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, К.Насыйри исемендәге премия лауреаты, Россия Федерациясе югары уку йортларының атказанган хезмәткәре Рәсимә Равил кызы Шәмсетдинова – минем өчен нәкъ менә шундый укытучы!



Үзендә татар хатын-кызларына хас аерым бер зирәклек, сабырлык, тыйнаклык, матурлык, затлылык кебек сыйфатларны туплаган әлеге ханым безнең, журналистика факультеты студентларының, күңелләрен беренче лекцияләреннән үк яулап алды, туган телебезнең байлыгын, мөмкинлекләрен күрергә өйрәтте, ана теленә хөрмәтебезне тирәнәйтте. Кешелекле мөнәсәбәте, гадилеге, көләч йөзе, мөлаемлыгы, тирән белеме, югары компетентлылыгы өчен яраттык без аны. Бервакытта да Рәсимә апаның тавыш күтәрүен ишеткәнебез булмады. Матур тавышы, дөрес, төзек сөйләме белән дә әсир итте ул безне. Әле бүген дә: «Эх, Рәсимә апа кебек булырга иде ул», – дигән уйларга биреләм, аның шәкерте булуым белән горурланам.

### Балачак хатирәсе

Биектау районының Мүлмә авылында туып, Ямаширмәдә үскән кыз ул Рәсимә апа. «Алма агачыннан ерак төшми», диләр – дөрес икән. Рәсимә Равиловнаның әтисе дә, әнисе ягыннан дәү әтисе дә укытучы, үз чорының зыялы кешеләре булганнар. Әнисе ягыннан әбибабалары шәхес культы елларының бөтен ачысын төчесен кичергәннәр. Башта кулак балалары, аннан соң «халык дошманы» ярлыклары эленә аларга. Хәтта Ленинград блокадасын үзүдә катнашып, Берлинга барып җиткән һәм 1947 нче елда гына сугыштан кайткан дәү әтисен кабат гаепләп кулга алалар, сугышта бирелгән орден-медальләрен, өйдә булган барлык мал-мөлкәтләрен конфискациялиләр. Гаиләгә бу гаделсезлек дип аталган авыр йөкне күтәрү гаять читен була. Алга таба яшәү өчен үтә дә нык, сабыр, яңадан аякка басу өчен бик тырышырга кирәк була.

Дәү әтисе 1955 елда гына кайта. Әанының гаепсез булуы турындагы аклау кәгазен гаиләсенә үзе үлгәч кенә тапшыралар.

«Әни бик тырыш,эшчән, киң күңелле кеше иде. Миңа өч ай булганда, билгеле сәбәпләр аркасында алар әти белән аерылышканнар. Ләкин әни бервакытта да мине әти ягы туганнарыннан аермады, алар белән үзе дә аралашып яшәде. Мин аларның бер-берсен ихтирам итүләрен тоеп яшәдем. Гомере буена җаваплы эшләрдә эшләде. Авыл халкы җылылык, рәхмәт хисләре белән искә ала әнине», – дип сөйли Рәсимә Равиловна.

Үзен укыткан укытучыларын, укыган мәктәбен җылылык, тирән ихтирам белән искә ала ул. Мәктәп еллары пионер дружинасындагы, комсомол оешмасындагы актив тормыш белән исендә калган аның. Рәсимә мәктәптә укыганда дружина советы председателе, комсомол оешмасы секретаре булып, төрле конкурсларда катнашып, ике тапкыр «Орленок», бер тапкыр «Артек» лагерена путевка белән бүләкләнә.

### Агач – җимеше, кеше – эше белән...

Рәсимә Равиловна, мәктәпне тәмамлаганнан соң, тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Нинди генә бөекләр укытмаган ул чорда Казан университетында! Рәсимә апага да Нил Юзиев, Ибраһим Нуруллин, Мөһәммәт Мәһдиев, Хатыйп Госман, Зәет Мәҗитов, Шәйхи Садретдинов, Диләрә Тумашева кебек легендар шәхес-остазлардан лекцияләр тыңларга насыйп була. Фәнни җитәкчесе – Алмазия Хаҗиевна Нуриеваны аерым бер җылылык, хөрмәт белән искә ала Рәсимә апа. Үз вакытында алтаистика өлкәсе белән кызыксындырып, Бурятиягә диплом язарга җибәргән була ул аны. Рәсимә Равиловна «Ул мине бик күп әйбергә өйрәтте, күп галимнәр белән таныштырды, Уфа, Алма-Ата, Мәскәү, Ленинград шәһәрләренә конференцияләргәҗибәрде. Алмазия Хаҗиевна тирән белемле, гадел, таләпчән һәм көчле шәхес иде», – дип сөйли Рәсимә апа.

Университетның 3 курсында укыган студентка уку белән бер үк вакытта Казан курчак театрында эшләргә тәкъдим ясала һәм ул бик теләп риза була. Биредә ул балаларны спектакльләрне кабул итәргә әзерли, спектакльдән соң алар белән әңгәмәләр уздыра, рәсемнәр ясата, төрле чаралар уздыра, шулай ук театрның тарихы буенча бай материал туплый, актерларның иҗади портретларын чагылдырган мәкаләләр язып, матбугатта чыгыш ясый. Театрны, коллективны бүген дә сагынып искә ала Рәсимә апа. Университетны тәмамлагач та, бер ел шушында эшли. Аннан соң инде аны Казан педагогия училищесына эшкә чакыралар. Кая гына барса да, Рәсимә апага һәрвакыт яхшы кешеләр очрап торган. Бәлки, үзе шундый яхшы күңелле кеше булгангадыр? Педучилищеда аны Вера Абрамова, Олимпиада Васильева, Виолетта Җәләловна, Серафима Петровна кебек чын педагоглар үз укучылары итеп кабул итәләр. Укытучы ничек киенергә, класска ничек керергә тиешлеген дә, журналны ничек тотырга кирәклеген дә нәкъ менә алардан өйрәнә. Укытучы буларак формалашуы да шул коллективта була аның.

Педучилищеда татар теле сәгатьләре кыскартылу сәбәпле, Рәсимә Равиловна Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына эшкә күчә. Биредә ул күренекле галимнәр, бөек шәхесләр белән таныша, алар аңа фәннитикшеренү эшчәнлегенә кереп китәргә ярдәм итәләр. Татар телен гамәлгә кую юнәлешендә дә актив эш башкара. Күп оешмалар каршындагы курсларда татар телен өйрәтә, пропагандалый. Югары партия мәктәбендә берничә ел татар теле укыту тәҗрибәсен Н.Х.Шарыпова белән берлектә «Татарский язык за 20 уроков» исемле кулланмада чагылдыралар. Бу кулланма әлеге юнәлештә чыккан хезмәтләрнең тәүгеләреннән берсе булып тора.

1991 елдан бирле Рәсимә Равиловна Казан университетында эшли. Параллель рәвештә кабат педучилищеда сәгатьләр бирәләр аңа. Шул ук чорда Казан дәүләт консерваториясенең татар музыкасы теориясе кафедрасында да студентларга татар телен укыта, ТР Дәүләт Советында татар теле өйрәтә. Бу елларны Рәсимә апа бик кызыклы һәм иҗади эшчәнлек чоры буларак искә ала.

Рәсимә Равиловна 1999 елда «Татар телендә медицина терминологиясе» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Татар халкының тормышына, яшәешенә көнчыгыш медицинасының йогынтысы гаҗәеп зур дип саный галимә. Болгар чоры медицинасы, аның чыганаклары турында бик теләп, нигезләп, яратып яза һәм сөйли галимә. Аның бу өлкәгә багышланган монографиясе, 150 дән артык мәкаләсе басылып чыккан.

Рәсимә Равиловна Республикабыз мәктәпләре белән дә, Мәгарифне үстерү институты белән дә тыгыз элемтәдә яши. Озак еллар дәвамында Казанның 39 нчы мәктәбе, Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге лицее белән хезмәттәшлек итә. Мәктәптә эшләү тәҗрибәсенә таянып, автордашлары И.Т.Мияссарова, Ф.Ш.Гарифуллина белән берлектә «Әлифба» укуукыту комплектын, автордашы Г.В.Һадиева белән «Поликультурное образование» сериясенең татар теле дәреслекләрен язуда катнаша.

Кайда гына хезмәт куймасын, Рәсимә Равиловна үзенең эшен яратып, җанын биреп башкара. Ул «Эшләгәнем кешегә булса, өйрәнгәнем үземә», –дигән принцип буенча яши.

### Матурлык фәлсәфәсе

Күп еллар дәверендә ничәмә-ничә балада туган телгә мәхәббәт уяту, милли үзаң тәрбияләүгә көчен кызганмаган Рәсимә апа үз балаларын да милли җанлы, итагатьле, белемле кешеләр итеп тәрбияләгән. Бүген Рәсимә апа яраткан хатын, кадерле әни, оныкларын иркәләүче дәү әни, олы җанлы кайнана да. Тормыш иптәше белән 1977 елдан бирле иңне иңгә куеп яшиләр, ике уллары бар. Рәсимә Равиловна һәм аның тормыш иптәше һәрвакыт улларына үрнәк булырлык итеп яшәргә тырышканнар. Ике як туганнарын үзара аермау, килгән кешегә һәрчак ачык чырайлы, хәер-хаклы булу, кунакларны олылап, кадерләп кабул итү, кеше сөйләмәү, гомумән, намуска каршы килә торган гамәлләр кылмау – Рәсимә апаның гаиләдәге төп әхлакый принциплары. Бала бит әти-әнисенең һәр эш-гамәлен сеңдереп үсә. «Дөресен әйткәндә, махсус бала тәрбияләп утырырга вакыт та, мөмкинлек тә булмады. Тормышны тартырга, берничә эштә эшләргә туры килде. Алар берсен-берсе тәрбияләде, дисәк тә ялгыш булмас. Балалар безнең алар өчен таяныч булуыбызны, аларны теләсә кайсы ситуациядә аңлаячагыбызны, ярдәм итәчәгебезне белеп, аңлап үстеләр. Без гаиләдә балаларга бервакытта да тавыш күтәрмәдек. Гомумән, балалар үзләренең кадерле булуларын, яратылуларын тоеп үсәргә һәм үзләре дә яратырга өйрәнергә тиешләр. Яратырга өйрәтү – үзенә күрә бер сәнгать ул»,– ди Рәсимә апа үзе бу уңайдан.

Аныңча, тормышта, нигездә, яхшылык та, начарлык та хатын-кыздан. «Табигать үзе шулай яраткан инде ул: хатын-кызда акыл, сабырлык булса, гаиләнең дә нигезе нык була. «Ачу – дошман, акыл – дус, ачуыңа акыл куш» –, дип кабатлый иде безнең дәү әни. Кешене көнчелек, комсызлык, канәгатьсезлек хисе эчтән кимерә, картайта, бу хисләр акрынлап аның дәвалап булмаслык авыруларына әйләнә. Бу турыда көнчыгыш табибфәлсәфәчеләре бик күп язып калдырганнар. Тормышта канәгать булып, тирәяктагыларга ярдәм итеп, җылылык өләшеп яши белү – матурлык инде ул», – дип саный Рәсимә Равиловна.

Ике улы – ике шатлыгы, мактанычы аның. Алар икесе дә гаиләле. Уллары, киленнәре, оныклары, кода-кодагыйлары турында аеруча җылылык белән сөйли Рәсимә Равиловна. Уллары икесе дә университет тәмамлап, җаваплы эшләрдә эшлиләр, икесе дә аспирантура тәмамлаган. Олы улы юридик фәннәр кандидаты, кечесе – икътисад өлкәсенә караган хезмәтен тәмамлап килә.

Бүген дә кызларны көнләштерерлек чибәр, сөйкемле һәм һәрвакыт эштә, тынгысыз хезмәттә Рәсимә апабыз. Күптән түгел Болгарда ачылган һәм шул чордагы медицина тарихын чагылдырган «Табиб музее» өчен булган материалларны тәрҗемә иткән ул. «Эшлегә көн җитми, эшсезгә көн үтми», – Рәсимә апага туры килә торган мәкаль. Чөнки ул эшле дә, эшлекле дә – чын замана хатын-кызы!

## • Вакыйгалар әзеннән

Шушы көннәрдә КФУда үзенчәлекле чара – «The Louis M.Brown and Forrest S.Mosten International Client Consultation Competition ICCC-Russia – 2014» **ХОКУКЫЙ КОНСУЛЬТАЦИЯЛӘҮ ХАЛЫКАРА БӘЙГЕСЕНЕҢ МИЛЛИ ЭТАБЫ ҺӘМ ГАМӘЛИ СЕМИНАР – ТРЕНИНГ БУЛДЫ**. Анда илебезнең эре югары уку йортларын тәкъдир иткән 14 команда катнашты. Проект «Юридик клиникалар үсеше үзәге» (Мәскәү) автоном коммерцияле булмаган оешма белән берлектә уздырылды. Чара кысаларында Россия, АКШ, Яңа Зеландия, Бөекбритания, Төркия һ.б. илләрнең юридик клиник белем бирү өлкәсендә эшли торган халыкара һәм Россия экспертлары белән онлайн режимдагы түгәрәк өстәл, тренинг, мастер-класслар үткәрелде.

• • • •

Алабуга институтының физик тәрбия факультеты студенты **АЛИНӘ СӘЛИМУЛЛИНА ТХЭКВОНДО БУЕНЧА** Идел буе федераль округының беренчелегендә **I УРЫННЫ ЯУЛАДЫ**. Чарада Саратов, Ульян, Түбән Новгород өлкәләре, Татарстан һәм Башкортстан спортчылары көч сынашты. Алай гына да түгел, А.Сәлимуллина Татарстан Республикасы беренчелегендә дә яхшы күрсәткеч – «алтын»га ия булды.

• • • •

Күптән түгел Биектау поселогында **X БӨТЕНРОССИЯ БИЛБАУ КӨРӘШЕ БУЕНЧА ТУРНИР БУЛДЫ**. Ул Россиянең атказанган тренеры М.М.Сәхабетдинов истәлегенә һәм Россиянең атказанган тренеры А.Ш.Шәйхетдинов бүләгенә лаек булу өчен ярыш буларак оештырылган иде. Чарада Россия Федерациясенең төрле өлкәләреннән 200гә якын спортчы катнашты. Шулар арасыннан Алабуга институтының I курс студенты **ФАИЛ ХӘЙРЕТДИНОВ,** ирекле стильдә чыгыш ясап, **III УРЫНГА ЛАЕК ДИП ТАБЫЛДЫ**.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

Тарих сәхифәләре

# «Мәктәп»тән – «Мәгариф»кәчә!

100 еллык «Мәгариф» журналы тарихын берничә чорга бүлеп карарга мөмкин.

Аның башлангыч чоры итеп, «Мәктәп» журналын күрсәтергә кирәктер. Журналның авторлары арасында Г.Исхакый, Ф.Туктаров, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, С.Сөнчәләй, Һ.Атласи, М.Бигиев, Һади һәм Садри Максудилар, Г.Гобәйдуллин, М.Корбангалиев, Г.Баттал, Ф.Сәйфи-Казанлы, Х.Әбелхан, Н.Думави, С.Җәлал, В.Җәлал һ.б. да булган. Редакциянең Габдулла Тукай белән тыгыз бәйләнештә булганлыгын ассызыклап китәргә кирәктер, чөнки шагыйрь һәм публицистның анда биш шигыре дөнья күреп кала. 1914 елның аерым бер саны Тукай вафатының бер еллыгына багышлана һәм ул Г.Исхакыйның баш мәкаләсе белән ачыла.

Беренче Бөтендөнья сугышы башлангач, «Мәктәп» журналы чыгудан туктый, ә 1918 елда, «Гыйльми һәйәт»нең (ягъни хакимиятнең мәгариф органының) рәсми басмасы буларак, Г.Ибраһимов кулы астында «Мәгариф» журналы дөнья күрә. Шулай да Совет заманында аның тарихын 1913 елгы «Мәктәп»кә бәйләүдән тыелганнар. Моның сәбәпләре революциядән соңгы «Мәгариф»нең идеологик бурычларына барып тоташа, дип фаразларга мөмкин.

1918 елдан алып, 1930 елларга кадәрге чор беренче чор дип йөртелә. Инкыйлабтан соң чыга башлаган «Мәгариф»нең идеологик әһәмияте шул дәрәҗәдә зур булган ки, анда хәтта Мәскәүдәге дәүләт идеологларының да мәкаләләре чыккан. «Мәгариф» журналының идеологиягә шул дәрәҗәдә әһәмият бирүенең сәбәбе нәрсәдә? 1920 елларда ук әле Мәгариф комиссариатының вәкаләтләренә культура мәсьәләләре дә керә иде. Шуңа күрә, мәгариф органнарының рәсми басмасы буларак, «Мәгариф» журналы аларны да колачларга тиеш иде. «Мәктәп-мәгариф эшләре өстенә, журнал уку өйләре, клублар, китапханәләр, театрлар, музейлар, югары уку йортлары һәм фәнни учреждениеләр, гомумән, татар культурасының барлык тармаклары турында язарга тиеш иде», – дип яза «Совет мәктәбе» журналының 1960-1977 еллардагы баш мөхәррире Фатих Ибраһимов.

Журналның бик мөһим идеологик ролен раслаган тагын бер факт бар: 1922 елдан башлап, 1937 елга кадәр «Мәгариф» журналында баш мөхәррир вазыйфасын Мәгариф халык комиссарлары үзләре башкарган.

«Мәгариф»нең 1918 елда чыккан беренче номерларында ук инде укыту программалары урнаштырыла. 1921 елдан соң чыккан журналларда да укытучының көндәлек эшендә ярдәм итәрлек методик материаллар шактый. Бу чорда грамотага өйрәтү методларын камилләштерүгә багышланган материаллар бик күп очрый. Мәктәпләргә комплекслап укыту системасы, дальтон-план, лаборатор-бригада, проектлар методы кебек методлар кертелгәч, журналда аларның эчтәлеген аңлатуга, алар белән эшләү юлларын ачыклауга бәйләнешле мәкаләләр күп басыла.

1930 еллар Ф.Ибраһимов тарафыннан икенче чор дип билгеләнә. Бу чор «Совет мәктәбе» журналының киң тематикадан китеп, төп игътибарын мәктәп проблематикасына юнәлтүе белән характерлана.

Журнал әлифба реформасын үткәрүдә турыдан-туры үзе катнашты. 1939 елның алтынчы саны «Уку елы тәмамланды» дигән мәкалә белән ачылып китә. Шунда: «Барлык башлангыч, тулы булмаган урта һәм урта татар мәктәпләренең беренче һәм икенче классларында балаларны рус графикасы нигезендәге алфавит буенча өйрәтүгә 1939-40 уку елы башыннан керешергә», – дип, Татарстан Югары Советы Президиумының карары игътибар үзәгенә куела. Шунда ук әлеге эшне оештыруда хилафлыклар да тәнкыйть ителә: «Районнарда курслар оештырылмаган, орфография кагыйдәләре массовый тиражда бастырылып, урыннарга җитәрлек күләмдә җибәрелмәгән, шулай ук уку китапларын бастыру буенча да сизелерлек хәрәкәт юк. Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты менә боларга җитди игътибар бирергә тиеш... Бу яңа эшкә комачаулык ясарга тырышучыларга һичбер төрле юл куелмаска тиеш».

1936 елның октябреннән ул «Башлангыч мәктәп» исеме белән чыга башлады. Әмма бу киң укытучылар массасында ризасызлык тудырды. Татар мәктәпләренең рус мәктәпләренә караганда күп кенә үзенчәлекләргә ия булуы татар телендә махсус журналдан башка мөмкин түгеллекне күрсәтте. 1938 ел башыннан «Башлангыч мәктәп» дигән исем «Совет мәктәбе»нә алыштырылды, ул барлык татар мәктәпләре өчен уртак, күп профильле журнал булып китте. Икенче чор 25 ел вакытны үз эченә ала (1941-48 елларда журнал чыгудан туктап тора). Ул авыр сугыш һәм шәхес культы елларына туры килә. Бу хәл журналның эчтәлегенә сизелерлек тәэсир итә.

1936-1937 елларда аның күләме өч табакка чаклы кечерәя (1926 елларда ул 6-8 табак күләмендә чыгарыла, шуның өстенә аның «Кушымта»сы да була), авторлар составы ярлылана. Жөөөурнал күбрәк мәгариф эшенең гомумирәк мәсьәләләре тирәсендә әйләнә.

1941 елда журналның юбилее билгеләп узыла. Шушы уңай белән журналда урнаштылган теләкләрдә һәм тәнкыйть фикерләрендә «Совет мәктәбе» журналының җитди кимчелекләре турында әйтелә. Сугыш елларыннан соң «Совет мәктәбе» кабат чыга башлагач, редакциянең мәктәптәге укыту процессы һәм тәрбия эшләренең барлык темаларына үтеп керергә тырышуы сизелә.




Ә инде журналның өченче чоры 1958 елдан башланып, 1980 еллар ахырына кадәр бара дияргә мөмкин. Басма коммунистик идеология белән сугарылган булса да, «Совет мәктәбе»нең совет мәгариф системасын төрле яклап яктыртырга омтылу, чын фәнни-педагогик һәм методик журнал булып җитешү чоры бу.

Ф.Ибраһимов мәкаләсеннән аңлашылганча, өченче чорның алшарты буларак, 1958 елда кабул ителгән халык мәгарифе системасын тагын да үстерү турындагы яңа законга нигезләнү күз уңында тора. «1960 ел укытучысы 1920 еллардагы, 1930 еллардагы, хәтта 1950 еллардагы укытучы да түгел иде. Ул инде нәрсә эшләргә кирәген яхшы белә, шунлыктан, журналдан ничек эшләргә кирәклеген өйрәтүче, әйтеп, күрсәтеп бирүче материаллар көтә иде», – дип яза ул.

1990 елда журналның кабат «Мәгариф» дип атала башлавы ул аның исемен генә түгел, ә милли яңарыш дәверендә җисемен дә үзгәртү иде. Татарстан Республикасы суверенлыгы турында Декларация кабул ителгәч, журнал милли мәгариф системасын торгызуга, Татарстан Республикасы халыклары телләре турындагы Законны гамәлгә ашыруга, яңа төзелгән демократик дәүләт шартларында, мәгариф системасы аша күпмилләтле ТР халыклары вәкилләренең белем алуга конституцион хокукларын тәэмин итүгә үзеннән зур өлеш кертте. Элекке идеологик кыйммәтләр җимерелгәннән соң, үсеп килүче буынны тәрбияләү мәсьәләләрен хәл итү өчен, укытучылар «Мәгариф»кә мөрәҗәгать итте. Бу – «Мәгариф» журналының дүртенче чоры.

2000 еллар ахырында журнал үсешенең бишенче чорына керде. Теләсә нинди матбугат чарасы мәгълүмат бирү белән генә чикләнмәскә, укучылары өчен кирәкле булсын өчен, ул аларның реаль тормышында актив катнашырга һәм үзе дә актив иҗтимагый тормыш белән яшәргә тиеш. Укучылары аны үзенең яклаучысы, мәнфәгатьләрен кайгыртучысы буларак таныса, журналның киләчәге өметле булачак.

*Мәгълүмат чыганагы «Мәгариф» журналы*

# «Мәгариф»кә -100!

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты

Татар вакытлы матбугатының бай тарихы ерак үткәнгә барып тоташа. Узган ел үзенең бер гасырлык юбилеен каршылаган «Мәгариф» журналы моның шулай икәнлеген тагын бер кат дәлилләде.





Шушы көннәрдә, басманың 100 еллыгы уңаеннан, «Белем һәм тәрбия чарасы буларак татар журналистикасы» дип исемләнгән фәнни-гамәли конференция узды. «Татмедиа» ААЖ, «Мәгариф» журналы редакциясе, ТР Журналистлар берлеге, КФУ оештырган әлеге конференциядә Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтының татар журналистикасы кафедрасы укытучылары, аспирантлары һәм студентлары актив катнашты. Чараның пленар утырышы 26 февральдә «Татмедиа»ның конференцзалында үткәрелде. Анда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Журналистлар берлеге рәисе Р.Ратникова, ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Р.Вәлиев, «Татмедиа», Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре, ТР Мәгарифне үстерү институты белгечләре, институтыбыз мөгаллимнәре чыгыш ясады. «Мәгарифтән башка бер генә милләтнең дә, бер генә халыкның да киләчәген күз алдына китереп булмый. Бу «Мәгариф» журналына да кагыла. «Мәгариф» укытучылар журналы гына түгел, ата-аналар журналы булырга тиеш. Чөнки ата-ана – укытучының коллегасы», – дип белдерде Р.Вәлиев үз чыгышында.

Чыннан да, милли мәгарифе булмаган милләтнең киләчәге шикле. Күп еллар дәвамында укытучыларның өстәл журналына әверелгән «Мәгариф» милли мәгарифне үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә. Р.Ратникова да бу фикерне куәтләп: «Бер гасырлык тарих – ул бик зур тарих. «Мәгариф»тә башкалардан аерылып тора торган журналистлар эшли. Бу – махсуслашкан журналистиканың аерым өлкәсе. Ник дигәндә, биредә һәрвакыт күңеле белән укытучы булган журналистлар эшләде», – дигән фикер җиткерде. Шул ук көнне ТР Журналистлар берлегендә оештырылган түгәрәк өстәлдә туган телне өйрәтүдә заманча технологияләрне куллану мәсьәләсе күтәрелде. Бу уңайдан төрле фикерләр яңгырады.

27 февральдә исә конференциядә катнашучылар институтыбыз аудиторияләрендә чыгыш ясады. «Белем һәм тәрбия бирүдә гаммәви коммуникация чаралары һәм яңа технологияләрнең роле», «Татар журналистикасында мәгариф басмаларының үсеше», «Мәгърифәтче журналистлар мирасы», «Басма һәм электрон мәгълүмат чараларында сөйләм культурасы проблемалары» дип исемләнгән секция утырышларында, институт мөгаллимнәре һәм студентларыннан тыш, читтән килгән кунаклар да чыгыш ясады. «Белем.ру» порталы җитәкчесе Р.Гатауллин татар мәгарифен үстерүдә Интернет челтәренең әһәмияте хакында кызыклы чыгышын тәкъдир итте. Казандагы 96 гимназия укытучысы Г.Тарханова исә белем бирү өлкәсендәге тәҗрибәсе белән уртаклашты, тыңлаучыларны шәхси сайты белән таныштырып, шәхси сайтларның мәгарифне үстерүдәге роле турында бәйнә-бәйнә сөйләде.

Конференциядә тәкъдим ителгән чыгышларның тулы варианты махсус җыентыкта бастырылачак.

● Халыкара хатын-кызлар көне

# 8 март өчен Клара Цеткинга рәхмәт

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Халыкара хатын-кызлар көне – күп кеше өчен яз, яңа тормыш бәйрәме. Әйтерсең, асыл затларыбыз күңеленнән сирпелгән җылылык карларны эретә, дөньяга ямь өсти.



Һәр бәйрәмнең үз тарихы булган кебек, бу көнне бәйрәм итү дә очраклы хәл түгел. XX гасыр башында хатын-кызларга хезмәт хакын ирләргә караганда азрак түләгәннәр. Аларга инженер, табиб, хокук сакчысы булу, үзләре теләгән уку йортына керү мөмкинлеге бирелмәгән. Әлбәттә, мондый хәл хатын-кызларны канәгатьләндермәгән. Һәм, 1908 елның 8 март иртәсендә, Нью-Йоркның меңләгән хатын-кызы, коллыкка түзә алмыйча, эш ташлап, ирләр белән тигез хокук таләп итеп урамга чыга. Бернигә карамастан, кулларына сабыйларын күтәргән аналар сафы арта бара. Демонстрацияне хәтта полиция дә куркыта алмый.

Шушы вакыйгадан соң, Америкада февральнең соңгы якшәмбесе хатын-кызлар бәйрәме буларак игълан ителә. Бәлки, без хәзер дә яз бәйрәмен бу көнне каршылар идек, әмма 1910 елда Даниянең Копенгаген шәһәрендә күп илләрнең хатын-кыз вәкилләре үз хокукларын яклау мәсьәләсенә багышланган киңәшмәгә җыелалар. Әлеге чарада Германия Коммунистлар партиясен төзүчеләрнең берсе, немец революционеркасы Клара Цеткин гүзәл затларның хокуклары өчен көрәш бердәмлеге көне булдыру тәкъдиме белән чыга. Бәйрәмне, 1908 елның 8 март көнендә булган демонстрациягә багышлап, нәкъ шушы көнгә билгеләргә булалар. Ул көнне хатын-кызларга төрле митингларда катнашу, аларны оештыру рөхсәт ителә. Сүз уңаеннан шуны әйтергә кирәк, Клара Цеткин гомере буе хатын-кызлар хокукы өчен көрәшкән, Халыкара хатын-кызлар Комитетының җитәкчесе булган. Бу бөек революционер истәлегенә Казанда 1932 елда бер урамга Клара Цеткин исеме бирелә.

Безнең илдә 1965 елдан 8 март – рәсми төстә ял көне. Хәзер инде 8 март көнне митинг оештыручылар юк. Хатын-кызлар көчле затлар белән бер тигез хокуклы. Шуңа күрә бу бәйрәм яз, матурлык бәйрәме булып санала. Ул көнне хатын-кызлар – төп геройлар. Алга таба да шулай булып калсын иде. Сезнең һәрбарчагызны язның тәүге бәйрәме булган 8 Март – Халыкара хатын-кызлар көне белән ихластан котлыйбыз. Язның ягымлы кояшы яхшы кәеф, уңышлар алып килсен.

# Чын күңелдән...



Нинди бәйрәмне бүләкләрсез күз алдына китереп була? Килешәсездер, бүләкләр бәйрәмгә ямь өсти. Берәүләр аларны сайлаганда фантазияне эшкә җигә, икенчеләр тормышта иң кирәкле әйберләрне бүләк итәргә ярата. Ә безнең университетта укучы гүзәл затларның бәйрәм көнендә нинди оригиналь бүләкләр алганнары бар икән?

✦ **Регина Закирова, А.М.Бутлеров исемендәге химия институты:** Яшәгән-булган ди бер кыз. Үз янына бер кешене дә якын китермәгән, комплекслары белән көрәшергә тырышкан. Әмма бер матур көндә бик әйбәт бер егет белән таныша. Бу егет аңа гашыйк була һәм кызга, аның нинди матур, гүзәл икәнен исбатлар өчен, фотосессия тәкъдим итә. Ә 8 март көнне мәхәббәтенә әзер фотолар белән фотокитап бүләк итә. Шулай итеп кыз комплексларыннан котыла һәм чыннан да кемгәдер кирәк икәнен аңлый. Сүзнең кем турында барганын аңлыйсыздыр инде (*елмая*).

✦ **Лилия Закирова, Экология һәм география институты:** Мин чәчәкләр бик яратам. Алар булмаса, бер бәйрәмнең дә ямен сизә алмыйм. Былтыр, 8 март көнне уянгач, бүлмәнең ишеген ачтым, ә анда 101 роза утыра. Шатлыгымнан елап җибәрдем. Шундый бүләк әнине дә көтә иде. Бу шатлыклы мизгелләр өчен без әтиебезгә рәхмәтле.

✦ **Ләйсән Галиева, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты:** Төрле бүләкләр алганым бар, алар арасында кыйммәтле бүләкләр дә юк түгел. Әмма, дөресен генә әйткәндә, алар чын күңелдән бирелмәсә, гомер буена истә калмый. Тормышымда алынган иң оригиналь бүләкләрнең берсе – ул бертуган абыемның үз куллары белән ясаган букеты. Миңа ул вакытта 10, ә аңа 12 яшь иде. Оригами техникасы ярдәмендә ясалган букетта лалә, роза, акчәчәкләр бар иде. Аны алгач, аптырадым, кыз кеше булып та мондый матурлыкны ясый алмый идем мин. Абыем шундый букетны 3 ай буе әзерләгән! Мин аны әле дә саклыйм.

✦ **Дания Шәрифуллина, Психология һәм белем бирү институты:** Иң оригиналь бүләкне мин егетемнән алдым. Ул – песи баласы. Мин аның турында бик озак хыялланган идем. Әмма башкалада бу махсус токымны табып булмады. Егетем, аны алыр өчен, Мәскәүгә барган. Шуның кадәр көч куеп алынган бүләкне ничек кадерләмисең инде? Хәзер песигә 2 яшь, көн саен торып аны күргәч, мәхәббәтем турында уйлый башлыйм.

✦ **Юлия Хәсәнова, Икътисад һәм финанс интитуты:** Җавап бирә алмыйм. Миңа, гадәттә, бер типтагы бүләкләр бирәләр. Ә туганнар бөтенләй акча гына бирә. Имеш, кеше үзенә нәрсә кирәген яхшырак белә. Минем фикеремчә, бу бер дә дөрес түгел. Чөнки хатын-кызлар бәйрәме – ул яз, матурлык бәйрәме. Һәм бүләкләр дә чын күңелдән бирелергә тиеш. «Сиңа нәрсә бүләк итәргә», – дип сораучыларны да аңламыйм. Фантазияне эшкә җиксәң, менә дигән бүләк алып яки үз кулың белән ясап була.

● Дөнья үзебезнеке

Хатын-кыз... Нечкә билле, сылу гәүдәле, кыйгач кашлы, кара күзле, озын толымлы татар хатын-кызлары... Кем генә сокланмый аларга! Матур булуларына карамастан, үтә тыйнак, җыйнак, сабыр, түземле, кунакчыл, сынмас рухлы, батыр йөрәкле, үзенең милләте, дине өчен гомерен дә кызганмаган хатын-кызларның язмышлары кемнәрне генә кызыксындырмый да, кемнәрне генә борчымый?!

# Дөнья терәге – хатын-кыз



● **Мөхлисә Бубый** – беренче татар мөгаллимнәренең берсе, Россиянең Мөселман дөньясында хатын-кызлар өчен иң беренче мәдрәсәгә нигез салучы һәм беренче хатын-кыз казый. Ул бөтен гомерен татар халкын мәгърифәтле итүгә, аны алдынгы карашлы итеп тәрбияләүгә багышлый. Әмма Сталинның кансыз сәясәте бу фидакарь шәхесне дә аямый. НКВД төрмәләрендә җәзаланса да, атылуга хөкем ителсә дә, халкына һәм диненә хыянәт итми ул. Соңгы сәгатенә кадәр Мөхлисә Бубый үзенең рухи көченә һәм какшамас иманына таяна.



● **Кәшифә Тумашева** – татар хатын-кызларыннан беренче режиссер. Ул 1956 елда Республика күчмә театрына (хәзер К.Тинчурин исемендәге Татар Дәүләт драма һәм комедия театры) баш режиссер итеп билгеләнә. Биредә ул, чагыштырмача аз вакыт – 6 ел эчендә – 25тән артык спектакль куя. Ул вакыттагы татар театры өчен Кәшифә Тумашева яңалык була. Чөнки режиссер һөнәрен энергия сарыф ителү буенча шахтер яки асфальт түшәүче хезмәте белән чагыштыралар. Сынмас рух, нык ихтыяр көченә ия булган әлеге уникаль ханым үзенең бөтен тормышын татар сәнгатенә хезмәт итүгә багышлый.



● **Зәйнәп Якупова** – Совет хатын-кызлары комитеты, берничә тапкыр РСФСР Югары Суды әгъзасы, район һәм шәһәр Советлары депутаты, «Азат хатын» журналы редколлегиясе, ТАССР һәм РСФСР акушер-гинекологлары җәмгыятьләренең идарә әгъзасы, биш ел дәвамында Казан шәһәренең баш акушер-гинекологы булып тора. Ул – СССРда «акушерлык һәм гинекология» буенча профессор дәрәҗәсенә лаек булган беренче татар хатын-кызы. З.Н.Якупова эшчәнлеге «ТАССРның атказанган табибы», «ТАССРның атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр, Хезмәт Кызыл байрагы һәм II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденнары, медальләр белән бәяләнә.



● **Сара Шакулова** – педагог, мәгариф белгече, математикадан югары белемгә ия булган беренче татар хатын-кызы. Урта белем алганнан соң, ул Петербургтагы тәрбиячеләр әзерли торган курсларда укый. 1907 елдан соң, педагог Лесгафт оештырган ул курслар ябыла һәм С.Шакулова белемен дәвам итәр өчен Парижга китә, анда данлыклы Сорбонна университетына укырга керә һәм 1913 елда югары билгеле диплом ала. Ул бик күп дәрәҗәле урыннарда эшли. Мәскәүдә мәгариф наркомында эшләгән вакытта, Әсәдуллаев йортындагы мөселман мәктәбе нигезендә татар телендә белем бирүче Нариманов исемендәге урта мәктәп ача, аның директоры була. Математика, татар теле дәреслекләре яза. Гомеренең соңгы елларына кадәр Мәскәү югары техник уку йортларында математика фәнен укыта.



● **Мәхбүбҗамал Акчурина** – Беренче рус революциясе елларында матбугатка чыккан хатын-кыз язучыларыбызның берсе. 1908 елдан башлап «Шура»да, соңга таба «Сөембикә» журналында басылган хикәяләре, бала тәрбиясе, хатын-кыз тормышына кагылышлы мәкаләләре белән исеме таныла. 1911 елны «Шура»да чыккан «Иске әдәбиятымыз» исемле мәкаләсендә ул, татар матбугатында беренчеләрдән булып, халык авыз иҗатын җыю, язма әдәби мирасыбызны барлау һәм өйрәнү кирәклеге турында бәхәс ача, «Таһир-Зөһрә», «Сәйфелмөлек», «Йосыф-Зөләйха» кебек борынгы әдәби ядкәрләрне урынлы-урынсыз этеп-төртүләргә каршы ризасызлыгын белдерә, бу әсәрләрнең халыкка, яшь буынга эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү ягыннан әдәби кыйммәткә ия булуына басым ясый.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.